СОВЕТ
КОНОВАЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423719,Республика Татарстан
Мензелинский район, с. Коноваловка, ул.
Центральная, 5

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КОНОВАЛОВКА АВЫЛ СОВЕТЫ

423719, Татарстан Республикасы,
Минзәлә районы, Коноваловка авылы,
Центральная урамы,5

телефон: (85555) 2-34-47. E-mail
Kval.Mnz@tatar.ru
ОКПО 92640440 ОГРН 1021605552803 ИНН/КПП 1628002812/162801001

# КАРАР

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ КОНОВАЛОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

№ 1 «10» октябрь 2023 ел

## Җир салымы турында

Россия Федерациясе Салым Кодексының 31 бүлеге һәм Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Коноваловка авыл җирлеге Уставының 31 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Коноваловка авыл җирлеге Советы

КАРАР ЧЫГАРА:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Коноваловка авыл җирлеге территориясендә түләүгә мәҗбүри булган җир салымын билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Салым ставкаларын күләмендә билгеләргә:

1) җирле үзидарә органы тарафыннан карьерлар эшкәртү өчен билгеләнгән һәм файдаланыла торган җир кишәрлекләренә карата (гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару)0,03% ;

2) гомуми файдаланудагы автомобиль юллары төзү һәм алардан файдалану өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата 0,05% ;

3) кунакханәләр урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата 0,1% ;

4) торак фонды биләгән җир кишәрлекләренә карата 0,15% (торак фондына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокук өлешеннән тыш)яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән)

(индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләреннән тыш);

5) шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә карата 0,15% ,

6) бакчачылык һәм яшелчәчелек өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата, шулай ук дача, бакчачылык һәм яшелчәчелек берләшмәләре составындагы җир кишәрлекләренә карата 0,3% ;

7) бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук "Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып баруы турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында"2017 елның 29 июлендәге №217-ФЗ Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,3% ;

8) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата 0,3% (торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш);

9) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә торак пунктлардагы авыл хуҗалыгыннан файдалану зоналары составындагы һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган җир кишәрлекләренә карата 0,3% ;

10) Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән, оборонаны, иминлекне һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән җир кишәрлекләренә карата 0,3% ;

11) мәгариф, фән, сәламәтлек саклау һәм социаль тәэмин итү, идарә, физик культура һәм спорт, мәдәният, сәнгать, Дин объектларының административ һәм офис биналарын урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата 0,4% ;

12) җитештерү һәм административ биналар, сәнәгать, коммуналь хуҗалык корылмалары, матди-техник, азык-төлек белән тәэмин итү, сату һәм әзерләү өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата 0,7% ;

13) сәүдә, җәмәгать туклануы һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата 1,2% ;

14) Авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланылмый торган авыл хуҗалыгыннан файдалану өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата 1,5%;

15) гаражлар һәм автостоянкалар урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата 1,5% ;

16) башка җир кишәрлекләренә карата 1,5%.

3. Салым түләүчеләрнең түбәндәге категорияләрен җир салымы түләүдән азат итәргә:

3.1. гражданнар каберлекләре, парклар, скверлар, бульварлар, яр буйлары, чишмәләр, су башнялары, скважиналар, һәйкәлләр, пляжлар урнашкан җир кишәрлекләренә карата оешмалар, учреждениеләр.

3.2. 90 һәм аннан да күбрәк яшькә җиткән гражданнар;

3.3. Бөек Ватан сугышында катнашучы ветераннар һәм инвалидлар;

3.4. Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезенд бирелгән җирләр буенча күпбалалы гаиләләр.

3.5. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Коноваловка авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында»2022 елның 21 сентябрендәге №647 Указы нигезендә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары.

Салым ташламасы салым түләүче милкендәге һәм эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым салу объектына карата салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасы күләмендә бирелә.

4. Әлеге карар, 3 пункттан 3.5 пунктчасыннан тыш, РФ Салым кодексының 5 статьясы нигезендә законлы көченә керә.

3 пункты 3.5 подпунктының гамәли көче, әлеге карарның салым чорында физик затлардан җир салымын исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә 2021 елдан башлап ел саен кагыла.

5. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында»16.11.2022 ел № 2 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылырга тиеш.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Коноваловка авыл җирлеге башлыгы,
Минзәлә муниципаль районы
Коноваловка авыл җирлеге Советы рәисе ____________________С.А.Билалова